Россия Федерациясе фән һәм югары белем министрлыгы
Югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе
“Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты”
Филология факультеты

Галиуллин Р.Р.

# Курс эшен ничек язарга

Татар бүлеге студентлары өчен методик кулланма

Яр Чаллы – 2023

Методик кулланма Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты Гыйльми советы карары нигезендә басыла

**Бәяләүчеләр:**

Шәрипов Ә.М.  - филология фәннәре докторы, профессор;

Гәрәева Г.Ф. -  филология фәннәре кандидаты, доцент.

Галиуллин, Р. Р. Курс эшен ничек язарга (методик әсбап) = Как написать курсовую работу / Р. Р.Галиуллин. – Яр Чаллы : Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты, 2023. –  35 б.

*Әлеге методик кулланма* филология *факультетында белем алучыларга курс эшләрен дөрес һәм бу төр эшләргә куелган таләпләргә туры китереп язу өчен тәкъдим ителә.*

# КЕРЕШ

Курс эшләре югары уку йортында уку процессының мөһим өлеше булып тора. Курс эшен башкару югары уку йортында укучының белемнәрен системалаштырырга, аерым теманы тирәнтен үзләштерергә ярдәм итә.

Фәнни язма эш алымнары укучы фикерләрен дөрес формалаштырырга, анализларга һәм гомумиләштерә белергә, мантыйкый фикерләргә өйрәтә. Ә инде үз хезмәтен яклаган вакытта укучы публика алдында чыгыш ясау күнекмәләрен ныгыта, ораторлык талантын камилләштерә. Нәтиҗәдә, белем алучылар татар теле һәм әдәбияты, һәм аның төрле тармаклары, укыту методикасы мәсьәләләре буенча үзләренең белемнәрен тирәнәйтә, фәнни тикшеренү эшләрен мөстәкыйль алып барырга өйрәнә.

Филология факультетының "Туган тел һәм әдәбият", "Туган тел һәм әдәбият, чит тел", "Туган тел һәм әдәбият, рус теле" белгечлекләре буенча белем алучылар татар теленнән, татар әдәбиятыннан һәм туган тел һәм әдәбиятын укыту методикасыннан курс эшләре башкара.

Бу эшкә тотынганда, белем алучы алдында бик күп төрле сораулар килеп баса: эшне нидән башларга, нәрсәләргә күбрәк игътибар итәргә, библиографияне ничек төзергә, астөшермәләрне ничек бирергә, титул бите ничек язылырга, фәнни эшнең төзелеше нинди булырга тиеш, фактик материалны ничек тупларга һ.б. Тәкъдим ителә торган методик кулланма әлеге сорауларга җавап бирүне күздә тотып төзелде.

Фәнни тикшеренү өчен сайланган тема булачак һөнәр өчен мөһим, алга таба практикада кулланырлык булырга тиеш. Моннан тыш, курс эшенең темасы чыгарылыш квалификация эше буларак дәвам итәрлек булганда отышлы.

Курс эшен башкарганда алган тәҗрибә югары уку йортын тәмамлаганнан соң да фәнни эш белән шөгыльләнергә мөмкинлек бирә. Ул студентның эрудициясен, сәләтен күрсәтә торган катлаулы фәнни иҗат нәтиҗәсе, һәм ул мөстәкыйль рәвештә языла. Фәнни эш белем алучыдан киеренке хезмәт, тикшерү осталыгы һәм хатасыз башкаруны, әдәбият һәм чыганаклар исемлеген

соңгы елларда кабул ителгән дәүләт стандартларына туры китереп язуны таләп итә. Шул җәһәттән, бу методик кулланманың фәнни эшне язганда, чыганаклар, астөшермәләр белән эш иткәндә, гомумән, курс эшен яклауга әзерләү, яклау вакытында файдасы тияр, дип уйлыйбыз.

## КУРС ЭШЛӘРЕН ЯЗУНЫ ОЕШТЫРУ

### Фәнни эшкә куела торган таләпләр

Курс эшенең максаты – фәнни эш язу методикасын үзләштерү, белем алучыда чыганак һәм фәнни әдәбият белән эшләү тәҗрибәсен, тикшеренү эшенең нәтиҗәләрен тәкъдим итү күнекмәләрен булдыру.

Студентлар тарафыннан язылган курс эшенә куела торган таләпләр:

- Сайлап алынган теманың актуаль һәм моңарчы тикшерелмәгән (аз тикшерелгән) булуы;
- тикшеренү эшенең студент тарафыннан мөстәкыйль башкарылуы;
- эшнең логик эзлеклелектә булуы һәм фикерләрнең, фактларның мисаллар белән дәлилләнеп килүе;
- чыганакларның һәм фәнни әдәбиятның комплекслы анализы;
- нәтиҗәләрнең конкрет һәм дәлилләнгән булуы (параграф яисә бүлек ахырында иң кыйммәтле фикерләрне туплап, берничә җөмлә белән йомгаклап кую);
- махсус терминалогиянең кулланышы;
- эшнең язылышы техник һәм методик яктан бу төр эшләргә куела торган таләпләргә туры килергә тиеш.

Курс эше татар филологиясенең берәр фәнни мәсьәләсен тикшерү эше алып баруны күз алдында тота. Белем алучы, эшне язган вакытта, әдәби чыганакларны, фәнни-теоретик хезмәтләрне барлау белән библиографик исемлек төзү, мәсьәләнең өйрәнелү тарихын тикшерү кебек эшләр башкара. Шулай ук мөһим мәгълүматны аерып чыгару, материалны эзлекле рәвештә

бирү, бу мәсьәләгә үзенең карашын белдерү, фәнни нәтиҗәләргә аңлатмалар бирү кебек эшләрне башкарырга өйрәнә.

Курс эшенең планы теманың эчтәлеген тулысынча ачарга тиеш. Тикшерелә торган темага киң фактик материал һәм аның җентекле анализы китерелергә тиеш. Шулай ук табылган материал арасында сәбәп-максат элемтәләре дә булырга тиеш.

Фәнни эшне язган вакытта студент теге яки бу тел, яисә әдәби күренешләргә, материалга карата мөстәкыйль рәвештә үзенең мөнәсәбәтен белдерә. Һәр фикер, һәр гипотеза чыганаклар һәм астөшермәләр белән бирелгән әдәбият исемлегенә ишарә ясарга тиеш. Сүзгә сүз кулланылган материал цитата буларак һәм куштырнакларда бирелеп бара.

Эшне бәян итү логик эзлеклелектә, күплек сандагы беренче зат тарафыннан булырга тиеш. Мәсәлән, *безнең тарафтан тикшерелде, безнең уйлавыбызча, күрсәтергә омтылдык һ.б.*

Фәнни эшнең кереш һәм йомгак өлешләре, кагыйдә буларак, төп өлеш язылып беткәннән соң языла, чөнки кереш өлешендә файдаланылган әдәбиятка күзәтү, чыганакларга, фәнни әдәбиятка анализ, характеристика ясала. Эшнең максаты һәм бурычлары билгеләнә, методологик нигезе күрсәтелә, ә йомгакта тулаем эшнең нәтиҗәләре китерелә.

## Тема сайлау

Фәнни эшләр өчен темаларны кафедра укытучылары тәкъдим итә. Ул темалар башта кафедра утырышында карала, аларның актуальлек дәрәҗәсе, яңалыгы һәм теоретик әһәмияте тикшерелә. Темалар, гадәттә, кафедра галимнәренең фәнни-тикшеренү эшләренә, юнәлешенә нигезләнеп биреләләр. Укытучылар тәкъдим иткән темаларның берсен студент сайлап ала һәм җитәкче укытучыга хәбәр итә. Аерым очракларда, студент укытучыга үзенә якын булган теманы да тәкъдим итә ала. Тема, беренче чиратта, студентның үзендә кызыксыну уятырга тиеш. Аның ялгыш сайлануы фәнни эшнең дәвамлылыгын һәм нәтиҗәлелеген киметә. Чыгарылыш квалификация эше дәрәҗәсенә

җиткererлек курс эше темасын сайлау яхшырак.

Фәнни җитәкче белән бер фикергә килгәч, курс эшен язуның алдагы этабына күчәләр.

## Фәнни җитәкчелек

Курс эшенең язылышы белән “Татар теле һәм әдәбияты, аларны укыту методикасы” кафедрасы профессорлары, доцентлары, өлкән укытучылары җитәкчелек итә ала. Белем алучыларның фәнни җитәкчене үзләре сайлап алу мөмкинлеге бар. Әгәр студент бер мөгаллимгә дә язылмаса, кафедра карары белән, ул берәр җитәкчегә беркетелә.

Кафедра утырышында студентлар һәм аларның җитәкчеләре, фәнни – тикшеренү эшенең темасы язылган исемлек тикшерелә һәм раслана.

Җитәкче тикшеренү эшен язу дәвамында киңәшләрен, тәкъдимнәрен әйтә, эшнең барышын контрольдә тота, тик әзер нәтиҗәләр, әзер материаллар бирми.

### *Фәнни җитәкче белән студентның хокук һәм бурычлары*

Курс эшен язу процессында ике генә кеше катнаша: фәнни җитәкче һәм фәнни хезмәтне язучы студент. Аларның үз хокуклары һәм бурычлары бар.

*Фәнни җитәкче бурычлары:*

- курс эше өстендә эшләү өчен студентка биремнәр бирергә, аның үтәлү срогын билгеләргә;
- кафедрада расланган график буенча консультацияләр үткәрергә;
- тема буенча төп әдәбият тәкъдим итәргә, студент белән берлектә өйрәнү объектын һәм предметын, максат һәм бурычларны билгеләргә, төп өлешкә караган фактик материалны эшкәртүдә, нәтиҗәләр чыгаруда ярдәм итәргә;
- курс эшенә куела торган таләпләрнең үтәлешен тикшерергә;
- курс эше башкаруның төрле этапларында язылган текст белән

танышырга, студент тарафыннан башкарылган эшләрне контрольдә тотарга;

- курс эшенең куелган таләпләргә җавап бирүе турында яклауга кадәр бәяләмә язарга.

*Фәнни җитәкче хокуклары:*

- студент аның күрсәтмәләрен кире какса, эш графигын үтәмәсә, курс эше белән җитәкчелек итүдән баш тартырга.
- студент курс эшенә куела торган таләпләрне үтәмәсә, эшне яклауга тәкъдим итмәскә.

*Студент бурычлы:*

- җитәкче төзегән график буенча консультацияләргә йөрергә;
- курс эшен язу һәм яклау графигын үтәргә;
- эшне язу процессында туган барлык кыенлыклар турында фәнни җитәкчегә хәбәр итәргә;
- фәнни җитәкченең курс эшен язуга кагылышлы бөтен таләпләрен төгәл үтәргә.

*Студент хокуклы:*

- курс эше язуның беренче этабында, җитәкче белән килешеп, теманы бераз үзгәртергә яисә төзәтмә кертергә;
- төп сәбәбен дәлилләп, фәнни җитәкчене алыштыру өчен, кафедра мөдиренә мөрәҗәгать итәргә;
- фәнни җитәкче фикере белән туры килмәсә дә, үз фикерен дәлилләп, аны нигезләп, якларга.

## Курс эшен язуның календарь планы

Факультет советында темалар раслангач, фәнни җитәкче белән берлектә фәнни эшне язуның календарь планы төзелә. Анда түбәндәгеләр чагылыш табарга тиеш:

1) өйрәнелә торган тема буенча фәнни әдәбият җыю, аның белән танышу;
2) теманың өйрәнелү дәрәҗәсен билгеләү;

3) булган проблемаларны ассызыклап күрсәтү, хезмәтнең структурасын ачыклау, алга куелган гипотезаларны нигезләү;

4) фактик материал туплау, аны төркемләү һәм анализлау;

5) фәнни эшнең текстын, эчтәлегенә, структурасына туры китереп язу;

6) текстка төзәтмәләр кертү;

7) эшне тиешле таләпләргә туры китереп, фәнни җитәкчегә тикшерергә тапшыру;

8) фәнни җитәкченең киңәшләрен һәм күрсәтмәләрен үтәп, тикшерену эшенә төзәтмәләр кертү;

9) фәнни эшне якларга әзерлек.

Фәнни җитәкче консультацияләрнең көннәрен һәм сәгатьләрен билгели.

Эш процессында туган сораулары белән студент билгеләнгән вакытларда консультацияләргә килергә тиеш.

## Фәнни әдәбият белән танышу

Тема расланганнан соң, эшнең *хронологик кысалары* билгеләнә, тикшерү объекты тәгаенләнә. Фәнни җитәкче сайланган темага кагылышлы әдәбият исемлеген тәкъдим итә. Бу мәсьәләдә фәнни җитәкче юнәлеш бирергә тиеш, әмма студент җитәкче биргән хезмәтләрне өйрәнү белән генә чикләнергә тиеш түгел. Ул үзе дә фәнни, методик журналлардан теоретик материаллар тупларга бурычлы. Моның өчен уку йорты, шәһәр, район китапханәләрендә күп кенә материаллар белән эш итәргә кирәк булачак. Тупланган әдәбият исемлеге фәнни җитәкчегә күрсәтелә, андагы мәгълүмат ни дәрәҗәдә туры килүе, файдалы булуына игътибар ителә.

1. Җыелган материалны үзләштерү, теманы яктырту өчен мәгълүмат туплау – тема өстендә эшләүнең мөһим этабы. Укучы тикшерелә торган чыганакны җентекләп өйрәнгәндә китапханәдә (электрон китапханә дә күздә тотыла) эшләү барышында тематик каталоглардан файдалана ала, ягъни үзе өйрәнә торган темага кагылышлы барлык фәнни әдәбиятны карап чыга, шулар арасыннан үзенә аеруча кирәклеләрен сайлый. Иң мөһиме, авторның

фамилиясен һәм инициалларын, баш исемен, басылып чыккан елын, шәһәрен, нәшриятын, китапның бит санын дөрес итеп күчереп язарга кирәк. Югары уку йортының фәнни эшләргә куелган таләпләре тупланган нигезләмгә (Положение о нормоконтроле научно-исследовательских работ обучающихся в ФГБОУ ВО «Набережночелнинский государственный педагогический университет». – Набережные Челны: НГПУ, 2016) таянып, фәнни эшнең чыганакларын һәм әдәбият исемлеген тутыру, архив белән эшләгән очракта, документларның саклану урынын, нинди сан астында, кайсы бүлектә урнаштырылган икәнлеген ачыклау мөһим.

Кирәкле әдәбиятны дөрес куллануда библиографик картотека төзүнең әһәмияте зур. Темага караган фәнни-теоретик әдәбиятны өйрәнүне тарихи-хронологик тәртиптә түгел, ә “кире тәртиптә” алып бару отышлырак. Иң башта соңгы елларда чыккан әдәбият белән танышасың, аннары, эзлекле рәвештә, элеккерәк еллардагы чыганакларны өйрәнәсең. Нәтиҗәдә, искергән хезмәтләргә бүгенге көн югарылыгыннан торып бәя бирергә мөмкинлек ачыла, теманың кайсы яклары әле һаман да тиешенчә яктыртылмаганлыгы яки бәхәсле булуы ачыклана.Башка автор фикере хезмәттә сылтама рәвешендә куштырнаклар эчендә бирелә.

## Фактик материал туплау

Җитәрлек күләмдә фәнни әдәбият белән танышып, бу теманы ниндирәк аспекта тикшерергә икәнлеге һәм эштә нинди методлар һәм алымнар куллану кирәклеге ачыкланганнан сон, студент тикшерелә торган мәсьәләгә караган фактик материал туплау эшенә тотына. Татар теленнән фәнни-тикшеренү эше башкарганда, гадәттә, стандарт карточкалар ясарга туры килә. Һәр карточкага үзенең темасына туры килә торган бер генә тел факты теркәлгән мисал язылa. Әгәр ул җөмлә рәвешендә язып алынган булса, дәлил булып хезмәт иткән өлеше аерылып күрсәтелә. Җыелган материал җитәрлек күләмдә туплангач, аны максатка ярашлы итеп, системага китереп, төркемлиләр. Бер төркемгә караган тел фактларының бөтен үзенчәлекләрен дә тикшереп, аерым бүлек яисә

параграф итеп бирергә мөмкин, анда әлеге тел фактлары буенча ачыкланган нәтиҗәләрне урнаштыралар.

Әлбәттә, аерым бер курс эшендә бик күп еллар дәвамында басылган материалларны колачлау мөмкин түгел. Димәк, тикшерү өчен сайланган текстлар вакыты чикләнгән хронологик тәртиптә алына. Материалны темада күтәрелгән проблема яссылыгында уку, фактларга тирәнтен анализ таләп ителә.

Фәнни эшкә материал җыйганда иң беренче чиратта темага караган фәнни әдәбиятны, фәнни-нәзари төшенчәләр турындагы бәхәсле карашларны барларга кирәк.

Татар теле һәм әдәбияты буенча әзер библиографик китаплар бар, ә туган тел һәм әдәбиятын укыту методикасы буенча махсус библиографик белешмәләр юк. “Мәгариф”, “Фән һәм мәктәп”, “Фән һәм тел” журналларында татар теле, әдәбияты һәм аларны укыту мәсьәләләренә багышланган мәкаләләр даими чыгып тора. Кызыксындырган темага караган хезмәтләрне бу журналларның соңгы санындагы шул елда басылган мәкаләләр исемлегеннән табарга була.

## МЕТОДИК КИҢӘШЛӘР

Курс эше гадәттә түбәндәге өлешләрдән тора:

- титул бите;
- эчтәлек (титул бите һәм эчтәлектә бит саны күрсәтелми);
- кереш (3нче биттән башлана);
- төп өлеш (ул берничә бүлектән тора, һәр бүлек параграфларга бүленә). Эчтәлектә һәм текстта *төп өлеш* сүзе язылмый, бары бүлек исеме генә языла;
- йомгак;
- кулланылган чыганаклар исемлеге
- кушымта;
- шартлы кыскартылмалар исемлеге.

## Титул бите

Фәнни эш компьютерда Word форматында, Times New Roman гарнитурындагы шрифт белән 14 кегль үлчәмендә, 1,5 интервал белән җыела, А4 форматындагы кәгазьнең бер ягына бастырыла. Битнең сул ягында 3 см, уң ягында 1см, өстә 2 см, аста 2 см буш ара калдырыла.

Бит саны титул битеннән санала, әмма аңа да, «эчтәлек» битенә дә сан сугылмый. Фәнни эшнең кереше 3нче биттән башлана. Бүлек исеме калын шрифт белән яңа биттә бирелә, бүлекчә, параграф исемнәрен бүлек исеменнән, текстан ике юл төшеп һәм гади шрифт белән аерырга кирәк. Бүлекчә исеме уртада бирелә, тик ул алга таба буласы төп тексттан аерылмый. Бүлек, бүлекчә, параграф һ.б. исеменнән соң нокта куелмый.

*Беренче бит* – титул бите һәм ул катгый кагыйдәләргә буйсынып язылa (кушымта 3). Титул бите татарча һәм русча бирелә. Анда югары уку йортының, кафедраның исеме, курс эше, тема, белгечлек шифры, исеме, белем алучының фамилиясе һәм инициаллары, имзасы, фәнни җитәкченең гыйльми дәрәҗәсе, вазыйфасы, фамилиясе һәм инициаллары,имзасы шәһәр исеме, язылган ел күрсәтелә. *Тема*, атама куштырнаклар эчендә бирелми, болар барысы да битнең уртасында күрсәтелә.

## Эчтәлек

Эчтәлек (кушымта 4) икенче биттә бирелә, ул аерым бүлекләрнең, параграфларның билгеле бер тәртиптә килүен, аларның кайсы битләрдә урнашуын күрсәтә.

Эчтәлек, план буларак, гадәттә, темага караган әдәбият белән танышканда ук күзаллана. Баштарак ул якынча булып, материал туплау барышында еш кына тулыландырыла, конкретлаштырыла һәм соңыннан фәнни эшнең эчтәлеге итеп куела.

Төп өлеш берничә бүлеккә, ә бүлекләр бүлекчәләргә (параграфларга) бүленә. Һәр бүлек 2-3 бүлекчәне үз эченә алырга мөмкин. Бүлекчәләр күләме ягыннан бер-берсеннән нык аерылмаска тиеш. Бүлек һәм бүлекчәләрнең

исемнәре төп проблеманың аерым тармаклары рәвәшендә бирелә. Гадәттә, һәр бүлек ахырында кыскача нәтиҗә ясала. Текст эчендәге бүлек һәм параграфларның исеме эчтәлектәге атамаларга һәм анда күрсәтелгән битләргә туры килергә тиеш. Кереш, бүлек исемнәре йомгак, библиография, кушымталар, текста яңа биттән башлап, калын хәреф белән языла. Бүлекчә атамалары төп тексттан ике интервал аша баш хәрефтән башланып, калганнары гади юл хәрефе белән уртада бирелә.

## Кереш

Кереш (кушымта 2, кушымта 5) – теләсә нинди фәнни-тикшеренү эшенең мөһим һәм җаваплы өлеше булып санала. Ул эш белән танышучыны алда китереләчәк мәгълүматны кабул итәргә әзерли. Кереш бер төрле «визит карточкасы» функциясен үти, башка тикшеренүчеләр өчен тәкъдим ителә торган эшнең кыйммәтен һәм мөһимлеген күрсәтә.

Студентлар тарафыннан башкарылган курс эшенең кереш өлеше 3 биттән торырга мөмкин. Монда теманың актуальлеге, аны ни өчен сайлау нигезләнә, максат һәм бурычлар билгеләнә, өйрәнү объекты һәм предметы ачыклана, тикшеренү методлары һәм алымнары турында әйтелә. Теманың өйрәнелү дәрәҗәсе, теоретик һәм гамәли әһәмияте күрсәтелә. Эшне язган вакытта төп таяныч булган фактик материаллар, чыганаклар күрсәтелә, төзелеше хакында кыскача языла. Әгәр хезмәт апробация үткән булса, бу турыда да искәртелә.

Керештә таблицалар, график, схемалар китерелми.

Фәнни эшнең *актуальлеге* хәзерге заман өчен тикшерелә торган күренешнең, процессның мөһимлеге, заманча фикерләүнең бу мәсьәләгә мөнәсәбәте-бәяләмәсе күрсәтелә, ягъни эшнең актуальлеге дигәндә, тикшерелә торган мәсьәлә ничек, ни рәвешле бүгенге көн мәдәни, иҗтимагый-сәяси, бәлки икъдисади процесслар белән кисешүе яисә бәйләнештә торуын күрсәтү була.

Эшнең актуальлеге берничә абзацтан башлап бер биткә кадәр була.

Төрле өлкәләрдә язылган теләсә нинди фәнни эшнең мөһим өлеше булып аның *объектын* һәм *предметын* билгеләү тора. Аларны билгеләү һәрвакыт

билгеле бер кыенлык һәм күп сораулар тудыра. Объект – процесс яки күренешне өйрәнү, тикшерү өчен проблемалы ситуация барлыкка китерә торган җирлек. Предмет – ул объект чикләрендә булган материал.

Туган тел һәм әдәбиятыннан курс эше язганда тикшерү объекты булып, гадәттә, урта гомуми белем бирү этабында өйрәнү каралган *тема* сайлана (мәсәлән, татар әдәбиятыннан өйрәнелә торган язучы иҗаты). Тикшерү предметы итеп әлеге язучы иҗатының берәр үзенчәлеге алынырга мөмкин. Шулай ук курс эшенең бурычлары күрсәтелә.

Мәсәлән, курс эшенең объекты – Р.Харисның «Ант суы» поэмасы, эшнең предметы – поэмадагы тарихи чынбарлык һәм уйдырма.

Курс эшенең максаты – Р.Харисның «Ант суы» поэмасында тарихи чынбарлыкны һәм уйдырманы билгеләү һәм чагыштыру.

Курс эшенең бурычлары:

1) Ренат Харисның тормыш юлына, иҗатына күзәтү ясау;

2) «Ант суы» поэмасының идея-эчтәлеге белән танышу;

3) поэмадагы тарихи вакыйгаларны барлау;

4) әсәрдәге тарихи вакыйгалар белән чын тарихи вакыйгаларны чагыштыру;

5) тема буенча фәнни-теоретик, тәнкыйди хезмәтләр һәм чыганаклар белән танышу).

Керештә *методологик нигезне* күрсәтү сорала. Ул фәнни эшне язган вакытта конкрет методлар һәм чараларны куллануны күз алдында тота:

1) типиклаштыру – бик күп төрле билгеләр арасыннан охшаш һәм төрле булган билгеләрне, аларны берләштерә торган бер модельгә яисә типка туплау;

2) сайлап алу методы – гадәттә бу метод киң теоретик материал булмаган очракта, өйрәнелә, тикшерелә торган күренешләрне тагы да җентекле рәвештә, төгәлрәк тикшеренүләр үткәрер өчен кулланыла. Бу метод күренешнең кайбер якларын гына тикшереп, башка күренешләр турында нәтиҗәләр ясарга ярдәм итә;

3) чагыштыру методы – төрле телләрдәге охшаш күренешләр, вакыйгалар, мәсьәләләр чагыштырып тикшерелә. Бу метод ярдәмендә күренешләр арасында бәйләнешне, фактик материалның охшаш һәм аерымлыкларын күрсәтергә ярдәм итә;

4) статистик методы. Бу метод ярдәмендә теге яисә бу күренешнең куллану ешлыгы, дәрәҗәсе статистик санау ярдәмендә күрсәтелә. Нәтиҗәләр төрле диаграммалар, схемалар, графиклар, таблицалар ярдәмендә күрсәтелә. Бу нәтиҗәләр охшаш күренешләр белән чагыштырырга мөмкинлек бирә.

*Фәнни яңалык* дип күтәрелгән мәсьәләнең беренче мәртәбә яктыртылуы, җентекләп өйрәнелүе, нәтиҗәләрнең яңа гына ачыклануы һәм әлеге материалларның моңарчы беркайда да яктыртылмавы исәпләнә.

*Эшнең гамәли кыйммәте* – фәнни эшнең төп нәтиҗәләрен гамәлдә куллана алу мөмкинлеге дигәнне аңлата һәм кайда, ни рәвешле кулланыла алуына ишарә ясый.

## Төп өлеш

*Төп өлешнең* бүлекләрендә логик эзлеклелектә бик җентекләп, фактлар һәм аргументлар китерелеп, тикшеренү материаллары бирелә. Барлык материаллар күләме буенча эшнең 2/3 өлешен тәшкил итәргә тиеш. Кагыйдә буларак, төп өлеш берничә бүлектән (2-3), ә алар үз чиратында 2-6 кадәр бүлекчәләргә бүленә. Һәрбер бүлек нинди дә булса максатка юнәлдерелгән була. Алдагысы шуннан соң килгән бүлеккә нигез булырга тиеш, ягъни куелган проблемаларның теоретик анализы була. Шуннан соң килгән бүлектә фактик материалны эксперименталь тикшерү яисә фәнни анализ нәтиҗәләре турында языла: текста таблицалар, графиклар, диаграммалар һ.б. китерелергә мөмкин. Төп бүлекне язган вакытта, түбәндәге тәкъдимнәрне истә тотарга кирәк:

1) бүлекләр һәм параграфлар исемнәре аларның эчтәлеген чагылдырырга тиеш: төгәл, конкрет, азсүзле булырга һәм ике мәгънәле булмаска тиеш;

2) һәрбер бүлекне, мөстәкыйль эчтәлеккә ия булган өлеш буларак, нәтиҗәләр төгәлләргә тиеш. Бу нәтиҗәләр китерелгән материалларны гомумиләштерергә һәм алдагы бүлеккә логик күчеш формасында булырга тиеш;

3) бүлек азагында китерелгән нәтиҗәләр тикшеренү этаплары буенча гомуми нәтиҗәләр чыгарырга ярдәм итәргә тиеш.

Студент куелган максат-бурычлар нигезендә өйрәнелә торган объектны анализлый, классификацияли, нәтиҗәләр чыгара. Студентның максаты проблемаларны күрсәтү генә түгел, үз карашыңны билгеләү, проблеманы ачуда аның үзенчәлеген табу, аңлау, анализлау, уңышлы мисаллар китерү. Кимчелекле яклары булса, сәбәпләрен ачыклау, дәлилләү, төзәтү юлларын әйтү.

Методик өлештә теге яки бу язучы иҗатын ФДБС таләп иткән яңа технологияләр ярдәмендә өйрәнүне күздә тотып эшләү сорала. Мәсәлән, тәнкыйди фикерләү, проект, коммуникатив, уен һ.б. технологияләр.

## Йомгак

Йомгакта укучы тикшеренү барышында алынган теоретик һәм гамәли нәтиҗәләрне яза, тик ул һәр бүлекнең нәтиҗәләрен санап чыгу гына түгел, ә эшнең гомумиләштерелгән нәтиҗәләре булырга тиеш. Шул ук вакытта аларның кыска һәм төгәл булулары зарури. Димәк, төп өлешне укымыйча да, йомгак аркылы эшнең асылы аңлаешлы булуы шарт. Аның күләме 2-5 бит тирәсе булырга мөмкин. Йомгакта астөшермәләр бирелми.

Күләме басма тексттан торган 30 биттән артмаска тиеш (кушымтаны кертмичә).

## Сылтамалар яки астөшермәләрнең бирелеше

Фәнни эшләрдә галимнәрнең, тел яисә әдәбият белгечләренең тикшерелә торган мәсьәләгә карашларын, төрле фикерләрен китермичә мөмкин түгел. Аларны тулаем текст өзеге итеп, ягъни цитата итеп бирергә була яки бу

фикерләр язылган хезмәтләргә ишарә генә ясарга мөмкин. Бу ишарәләрне башкача *сылтама* яки *астөшермә* дип атыйлар. Сылтамаларны текстта ике төрле бирергә мөмкин: текст эчендә һәм бит ахырында (астөшермәләр). Тик эшнең башыннан азагына кадәр боларның бары бер варианты гына кулланырга тиеш.

Астөшермәләр, алда әйтелгәнчә, бит азагында бирелә. Нумерация һәр биттә 1 номерыннан башланырга тиеш. Җөмлә азагында махсус астөшермә номеры куела, шулай эшләгән очракта гына, бит азагында хезмәтнең библиографик чыганакларын күрсәтү өчен юл барлыкка киләчәк. Моның өчен Word документының өстә урнашкан панелендә «Вставка», «Ссылка», «Сноска», «На каждой странице”, “Ко всему документу» дигән параметрларын сайларга кирәк.

Астөшерелмәләрдә хезмәт турында тулы мәгълүмат китерелә: авторы, исеме, чыккан урыны, нәшрияты, елы һәм текстның кайсы битләрдән алынганы.

Әгәр бер биттә бер үк хезмәткә рәттән ике яки өч тапкыр таянырга туры килсә, «Шунда ук» дип кенә языла. Бите үзгәрсә «Шунда ук. – Б.35» дип битен дә күрсәтергә кирәк. Түбәндә астөшермәләрнең бирелеше үрнәк итеп бирелә:

[1] Макарова, В.Ф. Хәсән Сарьян прозасының поэтикасы. Монография / В.Ф.Макарова. – Яр Чаллы: Яр Чаллы типографиясе, 2003. – 152 б.

[2] Шунда ук.– Б. 15.

[3] Шунда ук.

Текст эчендә китерелә торган сылтамалар төрлечә бирелергә мөмкин. Кафедра утырышында, эшләрдә төрлелек булмасын өчен, бары бер вариант сайлап алына һәм студентлар тарафыннан бары шул кабул ителгән сылтамалар кулланыла.

Библиографиядә күрсәтелгән хезмәтләр номерланган булса, квадрат җәяләр эчендә аның номеры һәм өтердән соң кайсы биттәге текст файдаланылганы күрсәтелә. Мәсәлән, [25, б.302].

Бер үк вакытта берничә хезмәткә таянганда, хезмәтләрне күрсәткән төркемнәр арасына нокталы өтер куела: [25, б.32; 36, б.45; 56, б.6].

Еш кына интернет ресурслардан да файдаланырга туры килә. Мондый очракларда сылтама интернет ссылка ярдәмендә күрсәтелә. Шунысы мөһим: җәяләр эчендә бу адреска мөрәҗәгать итү датасы күрсәтелергә тиеш. Мәсәлән, http//www.belem.ru ( мөрәҗәгать итү вакыты: 13.02.2019).

## Кулланылган чыганаклар исемлеге

*Кулланылган чыганаклар исемлегендә* бары курс эшен язганда реаль кулланылган чыганаклар һәм әдәбият исемлеге китерелергә тиеш. Әдәби чыганаклар һәм фәнни-теоретик хезмәтләр исемлеге аерым исемлекләр булып бирелә. Әдәби чыганакларда тикшерү материалы буларак кулланылган матур әдәбият әсәрләре, җыентыклары, шәхси хатлар, истәлекләр һ.б. күрсәтелә. Чыганаклар алфавит тәртибендә урнаштырылалар. Хезмәтләр алфавит тәртибендә, башта татар телендә, аннары рус, алардан соң чит телләрдә басылганнары урнаштырыла. Чыганаклар һәм әдәбият исемлеген түбәндәгечә бирергә мөмкин:

**Кулланылган чыганаклар исемлеге**

I. Әдәби чыганаклар

1. Юныс, М. Шәмдәлләрдә генә утлар яна: Повестьлар / М.Юныс. — Казан: Татар.кит. нәшр., 2003.— 230 б.

2. Юныс, М. Энҗе эзләүчеләр: Повесть, хикәя, новеллалар һәм юл язмалары / М.Юныс — Казан: Татар. кит. нәшр., 1999.—174 б.

II. Фәнни-теоретик хезмәтләр

Татар телендә

3. Макарова, В.Ф. Сатираның сәнгатьчә үзенчәлекләре. Методик

әсбап / В.Ф.Макарова. – Яр Чаллы: КДУның Яр Чаллы филиалы типографиясе. – 2007. – 56 б.

4. Миңнуллин, Ф. Балта явызлар кулында: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. (Т.Галиуллин кереш сүзе) / Ф.Миңнуллин. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1994. – 344 б.

Рус телендә

5. Макарова, В.Ф. Комическое как категория национального литературоведения / Материалы Международной научно-практической конференции «Межкультурная коммуникация в глобальном контексте: проблемы языка, литературы и методики преподавания» (12 апреля 2018 г.) / В.Ф.Макарова. – Актюбе: Актюбинский региональный государственный университет им. К.Жубанова. – 2018. – С.–7-11.

6. Макарова, В.Ф. Скрытая ирония в татарской прозе 20–30-х гг. // Наука и школа / В.Ф.Макарова. – Набережные Челны, 2014. – № 2. – С. 16-19.

Чит телдә

7. F. I. Gabidullina – B.S. Korganbekov – V.F. Makarova – R.A. Zakirov – G.F. Kayumova Concept «teacher» in language consciousness of students of philological faculty // XLinguae, Volume 12, Issue 3, June 2019, p. 45-54.

8. Kayumova, G. F., Makarova, V. F., Galiullin, R. R., Khaziev, R. I., Yuldybaeva, G. V., & Abdrafikova, G. K. (2018). Moral education of high school students in national (Turkic) schools through literature.*International Journal of Mechanical Engineering and Technology, 9*(10), 1467-1475.

9. Makarova, V.F., I. Gabidullina, F., Galiullin, R. R., I.Mubarakshina I.I., Zhundibayeva A. The Realization of the Hermeneutical Approach to the Text in Practical Classes in the Literature during the Work with Students of Philological Faculty (Web of Science, Scopus). Journal of Social Studies Education Research Sosyal Bilgiler Eğitimi Araştırmaları Dergisi 2018:9 (3), Pp. 226-240.

Әдәби чыганаклардан соң китерелгән фәнни-теоретик хезмәтләр исемлегендә нумерация яңадан башланмый, ә дәвам итә. Китапның

библиографик тасвирламасының схемасы түбәндәгеләрне чагылдырырга тиеш:

Авторның фамилиясе һәм инициаллары. Титул битендә күрсәтелгән китап исеме / (авыш сызык) Инициаллар һәм фамилия. – Нәшер ителү урыны: шәһәр, нәшрият исеме яки нәшер итүче оешма, нәшер итү елы. – Күләме. Мәсәлән:

Макарова, В.Ф. Комическое в татарской прозе XX века: [монография] / В.Ф.Макарова. – Набережные Челны: ФГБОУ ВПО «НИСПТР», 2013. – 187 с.

Журналдагы мәкалә булса:

Макарова, В.Ф. Типология комического / В.Ф.Макарова // Научный Татарстан. – 2014. – № 1. – С.108-116.

Авторлар саны 2-3 булса, фамилияләрне өтер аша күрсәтәләр. Мәсәлән: Заһидуллиина Д.Ф., Әминева В.Р., Закирҗанов Ә.М. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.

Хезмәт берничә томны тәшкил иткән очракның библиографик тасвирламасы: Китапның исеме: томнарның гомуми саны / Басма өчен җаваплылар. – Нәшер итү урыны: нәшрият исеме, беренче һәм соңгы томнарның нәшер ителү еллары. Мәсәлән:

Татар теленең фразеологик сүзлеге: 2 томда / Төз. Н.Исәнбәт. – Казан: Татар. кит. нәшер., 1989-1990.

Күптомлы басманың бер томы гына кулланылса:

Исәнбәт Н. Татар теленең фразеологик сүзлеге: 2 томда. – Казан: Татар. кит. нәшер., 1990. – Т.2. – 365 б.

Хезмәтләрнең библиографик тасвирламасын түбәндәгечә бирәбез:

*Бер авторлы хезмәтләр*

Әхәтов, Г.Х. Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге / Г.Х.Әхәтов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – 176 б.

Макарова, В.Ф. Истоки комического в татарской литературе // В мире научных открытий (Проблемы науки и образования) / В.Ф.Макарова. – Красноярск: Научно-инновационный центр, 2013. – №11(47). – С. 318-324.

Макарова, В.Ф. Футурологические прогнозы в повести Фатиха Амирхана «Фатхулла хазрат» (1909) // Физика и лирика. Материалы международной научной конференции «Физика и лирика: мировой опыт и реальности науки и литературы стран Содружества» (14-16 ноября 2018 г. / В.Ф.Макарова. – Баку и Шамахы, 22-23 ноября 2018 г. – Дубна). – Баку, «Элм», 2019. – С. 241-243.

*Ике – өч авторлы хезмәтләр*

Заһидуллина, Д., Йосыпова Н. XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 1: XX йөзнең беренче яртысында татар әдәбияты. – 230 б.

Заһидуллина, Д., Йосыпова Н. XXгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

*Дүрт һәм аннан артык авторлы китаплар*

Заһидуллина, Д., Закирҗанов, Ә., Йосыпова, Н., Гыйләҗев Т. Татар әдәбияты. Теория. Тарих / Д.Заһидуллина, Ә.Закирҗанов, Н.Йосыпова, Т.Гыйләҗев. – Казан: Мәгариф, 2006. – 364 б.

Макарова В.Ф., Хазиев Р.И., Галиуллин Р.Р., Мубаракшина И.И. Религиозные предания в поэзии Г.Тукая / Современные исследования социальных проблем. – 2017, том 9, № 3-2. http://soc-journal.ru – С. 373-379.

*Күптомлы яисә берничә кисәктән торган китапларның аерым томнарын бирү.*

Исәнбәт, Н. Татар теленең фразеологик сүзлеге: 2 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990.– Т.2. –365 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 1 том: А-В. – Казан: ТӘҺСИ, 2015. – 712б.

*Газета – журналларда басылган мәкаләләр*

Макарова, В.Ф. Зур әдип әзер хакыйкать белән яши алмый // Казан утлары / В.Ф.Макарова. —2001.—№7.—Б.148-151.

*Авторы күрсәтелмәгән китапларны бирү тәртибе*

Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге / Төзүчеләре Д.Ф.Заһидуллина, В.Р.Әминева, М.И.Ибраһимов, Н.М.Йосыпова, Ә.М.Закирҗанов, Т.Ш.Гыйләҗев, Г.Р.Гайнуллина. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.

Татарча-русча фразеологик сүзлек / Төз.Ф.С. Сафиуллина. – Казан: Мәгариф,2001. – 335 б.

Хәзерге татар әдәби теле: югары уку йортлары өчен дәреслек / җаваплы ред. Х.Курбатов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1965. – 300 б.

*Авторефератлар һәм диссертацияләрдән алынган материалларны күрсәтү*

Ахунзянов, Г.Х. О стилистических особенностях образных фразеологических выражений: автореф. дис. ...канд. филол. наук / Г.Х.Ахунзянов. – Казань, 1964. – 25 с.

Галлямов, Ф.Г. Лексико – грамматические особенности повторов в современном татарском языке: дис. ...докт. филол. наук / Ф.Г.Галлямов. – Уфа, 2007. – 398 с.

Хуснутдинова, Л.К. Современный татарский исторический роман (проблемы поэтики): автореферат дис. … канд. филол. наук / Л.К.Хуснутдинова. – Казан. гос. ун-т. – Казань, 2003. – 23 с.

*Норматив чыганакларны бирү*

Об образовании в Российской Федерации: Федер. Закон от 29 декабря 2012г., №273-ФЗ. – 2012. – 29 декабря. – 404 с.

Федеральный Государственный образовательный стандарт среднего (полного) общего образования: приказ Министерства образования и науки Российской Федерации от 17 мая 2012г., № 413 / Министерство образования и науки Российской Федерации. – Москва, 2013. – 27с.

*Электрон ресурсларны күрсәтү тәртибе*

Класстан тыш уку дәресләре, аларның төрләре, үткәрү методикасы: https://infourok.ru/klasstan-tish-uku-dreslre-alarni-trlre-tkr-metodikasi-1457648.html – (мөрәҗәгать итү вакыты: 20.09.2019.).

Башка вариантлар кабул ителми.

**Кушымта**

*Кушымтада* эшнең төп нәтиҗәләрен чагылдырган диаграммалар, схемалар, сүзлекчәләр җыелган фактик материаллар, дәрес эшкәртмәләре һ.б. бирелергә мөмкин. Әгәр эштә берничә кушымта урнаштырылса, алар номерлана, кайвакыт исемләнәләр. Хезмәттә автор кыскартылмалары кулланылса, кулланылган чыганаклар исемлегеннән соң шартлы кыскартылмалар исемлеге урнаштырыла.

## КУРС ЭШЕН ЯКЛАУ ТӘРТИБЕ

Фәнни эшнең караламасын студент яклауга якынча 15–20 көн кала җитәкчесеннән тикшертә. Титул битенә башта үзе кул куя, фәнни җитәкчесенең имзасын ала. Курс эшенә рецензияне җитәкче яза.

Гадәттә, белем алучы курс эшен махсус график буенча курсташлары һәм комиссия әгъзалары алдында яклый. Белем алучы 5-7 минут эчендә үз эшенең темасы, максат-бурычлары һәм төп нигезләмәләре, нәтиҗәләре белән таныштыра. Аннары аңа сораулар бирелә. Фәнни эш авторы сорауларга җавап

бирә, җитәкченең тәнкыйди фикерләренә, теләк-тәкъдимнәренә мөнәсәбәтен белдерә. Чыгыш төгәл, конкрет булырга тиеш. Видеоязма һәм аудиоязмалардан файдаланырга, презентациядә тикшеренүнең төп өлешен оригиналь рәвештә тәкъдим итәргә мөмкин.

Курс эшенә бәяне укытучылардан торган комиссия куя, фәнни җитәкченең бәяләмәсе дә исәпкә алына.

Әлбәттә, эшне бәяләгәндә комиссия тәкъдим ителгән фәнни хезмәтнең башкару сыйфатын, уку йортының фәнни эшләргә карата таләпләре тупланган нигезләмәгә туры китереп әзерләнгәнлеге белән беррәттән, студентның кыска гына вакыт эчендә үз хезмәтенең асылын аңлата, үз фикерен дәлилли белүен, фәнни дискуссия барышында югалып калмавын, аудитория алдында үз-үзен тотышын да исәпкә ала.

## Балл-рейтинг системасы регламенты

Кафедра утырышында фәнни эшне яклау графигы раслана һәм комиссия әгъзалары билгеләнә.

*Семестр дәвамында эш тәртибе*

| № | Эш төре | Вакыты | Балл |
|---|---|---|---|
| 1. | Вакытында тема сайлау; фәнни җитәкче белән аралашу | 15 окт. | **5** |
| 2. | Әдәбият һәм чыганаклар белән эшләү; курс эшен планлаштыру | дек. | **30** |
| 3. | Фәнни җитәкче янына киңәшкә бару; курс эшенең барышы белән таныштыру | уку елы дәвамында | **15** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4. | Курс эшенең вакытында үтәлеше һәм тапшырылуы | апр.-май | **5** |
| 5. | Курс эшенең тематикасы буенча фәнни-гамәли конференцияләрдә катнашып, чыгыш ясау (өстәмә балл) | гыйнв.- апр. | **5** |

*Аттестацияләү барышы*

| № | **Бәяләү критерияләре** | **Балл (иң югары – max) 40** |
|---|---|---|
| 1. | Фәнни эшнең эчтәлеге куелган максат һәм бурычларга, теманың актуальлегенә туры килүе | **10** |
| 2. | Студентның мөстәкыйль эшләве, фәнни тикшерүнең үзенчәлеге | **5** |
| 3. | Чыганаклар һәм фәнни әдәбият белән эшләве | **5** |
| 4. | Курс эшенең төзелеше, дәүләт белем стандартлары (ФГОС) таләпләренә туры килүе | **5** |
| 5. | Яклауда чыгыш ясау, сорауларга җавап бирү | **15** |

*Балларның билгедә чагылышы*

| **Балл** | **Билге** |
|---|---|
| 33–54 | «Канәгатьләнерлек түгел» |
| 55–70 | «Канәгатьләнерлек» |
| 71–85 | «Яхшы» |
| 85–100 | «Бик яхшы» |

## Бәяләмә язу тәртибе

Фәнни эшне яклар өчен аның башкалар тарафыннан укылган булуы, бәя бирелүе сорала. Курс эшләренә бәяләмәне гыйльми җитәкче яза (кушымта 1).

Бәяләмә (рецензия) язуның үз тәртибе бар. Фәнни җитәкче бәяләмәсе түбәндәге сорауларны үз эченә ала.

Фәнни эшнең эчтәлеге куелган максат-бурычларга, теманың актуальлегенә туры киләме?

1. Куелган сораулар нигезле дәлилләнгәнме?
2. Мөстәкыйль эшләү сыйфаты ни дәрәҗәдә?
3. Студент башкаларның хезмәтен өйрәнә һәм гомумиләштерүләр ясый алганмы?
4. Дөрес нәтиҗәләр чыгарылганмы?
5. Материалны өйрәнү дәрәҗәсе.
6. Фәнни эшнең кимчелекләре.
7. Фәнни эшнең киләчәктә кулланылышы.
8. Башкарылган эшкә билге.
9. Көне, имзасы.

## ФАЙДАЛАНГАН ӘДӘБИЯТ

1. Библиографическая ссылка. Общие требования и правила составления: издание официальное. – Москва : Стандартинформ, 2008. - URL: http://protect.gost.ru/document .

2. Галиева, Р. М. Фәнни язма эшләр, практика. Татар журналистикасы бүлеге студентлары өчен хисап тәртибе: укыту-методик кулланмасы / Р. М. Галиева, Л. Р. Сабирова. – Казан : Казан ун-ты нәшр., 2014. – 123 б.

3. Положение о нормоконтроле научно-исследовательских работ обучающихся в ФГБОУ ВО «Набережночелнинский государственный педагогический университет». – Набережные Челны : НГПУ, 2016.

4. Татар теленнән язма эшләр: студентлар өчен методик кулланма / Төз. Х. Х. Сәлимов. – Алабуга, 1998. – 22 б.

5. Туган тел һәм әдәбият белгечлеге буенча курс һәм чыгарылыш квалификация эшләре: студентлар өчен методик кулланма / Төз. Р. Х. Мөхиярова. – Казан : Школа, 2008. – 28 б.

# ЭЧТӘЛЕК

*Кереш.*..........................................................................................................3
*Курс эшләрен язуны оештыру*...........................................................................*4*
Фәнни эшкә куела торган таләпләр............................................................4
Тема сайлау.........................................................................................................5
Фәнни җитәкчелек...............................................................................................6
Курс эшен язуның календарь планы...........................................................7
Фәнни әдәбият белән танышу.......................................................................8
Фактик материал туплау............................................................................9
*Методик киңәшләр*...........................................................................................10
Титул бите.........................................................................................................11
Эчтәлек ..........................................................................................................11
Төп өлеш............................................................................................................14
Йомгак.................................................................................................................15
Сылтамалар яки астөшермәләрнең бирелеше...........................................15
Кулланылган чыганаклар исемлеге...............................................................17
Кушымта............................................................................................................22
*Курс эшен яклау тәртибе*....................................................................................*22*
Балл-рейтинг системасы регламенты..........................................................23
Бәяләмә язу тәртибе.......................................................................................25
*Файдаланган әдәбият*...........................................................................................*26*
*Кушымталар*

**Кушымта 1**

## КУРС ЭШЕ ҖИТӘКЧЕСЕНЕҢ БӘЯЛӘМӘСЕ

Тема________________________________________________________

Автор (белем алучы) ___________________________________________

Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты

Татар теле, әдәбияты һәм аларны укыту методикасы кафедрасы

Юнәлеш _____________________________________________________

Профиль

Фәнни җитәкче (исем-фамилиясе, эш урыны, вазифасы, гыйльми дәрәҗәсе, фәнни исеме)

КУРС ЭШЕНЕҢ ФГОС/ГОС ТАЛӘПЛӘРЕНӘ ТУРЫ КИЛҮ-КИЛМӘҮ КҮРСӘТКЕЧЕ

| Һөнәри әзерлеккә таләпләр | Туры килә | Нигездә туры килә | Туры килми |
|---|---|---|---|
| Курс эшен башкарганда бурычларны-максатларны уйлау һәм формалаштыру, анализлау, актуальлек һәм проблеманың килеп чыгу сәбәпләрен ачыклый белү | | | |
| Куелган бурычларны хәл итүнең өстенлекле якларын билгеләү | | | |
| Фәнни-теоретик хезмәтләрне куллана белү | | | |
| Һөнәри эшчәнлек өлкәсендә мәгълүматны җыю, саклау һәм эшкәртүнең (редакцияләүнең) компьютер ярдәмендә тормышка ашырыла торган алымнарын куллану | | | |
| Тупланган мәгълүматны анализлау һәм аңлатып җиткерүнең (интерпретацияләү) мөмкинлекләрен дөрес бәяләү | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Вакытны нәтиҗәле файдаланып, эш тәртибен дөрес оештыру (максат-бурычларны, объект-предметны ачыклау, фәнни тикшеренүнең яңалыгын, актуальлеген, методологик нигезне билгеләү, эшнең планын төзү, мәгълүмат туплау, эшкәртү, текстны язу, нәтиҗә ясау) | | | |
| Исәп-хисап нәтиҗәләрен объектив бәяләү | | | |
| Аңлатып җиткерү (интерпретация) һәм тәҗрибә (эксперимент) ярдәмендә табылган мәгълүмат нәтиҗәләрен анализлый белү | | | |
| Анализ алымнарын белү | | | |
| Хезмәттәшләр, курсташлар белән аралаша белү, эшчәнлек алып бару | | | |
| Фәнни эштә дәлилләнгән дөрес нәтиҗәләргә ирешә белү | | | |
| Һөнәри юнәлештәге фәнни әдәбият куллану | | | |

Эшнең өстенлекләре

______________________________________________________________________

Кимчелекләре

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

Нәтиҗә

______________________________________________________________________

Фәнни җитәкчесе ______________________________________________

2023 елның «   »_ __________________

## Кушымта 2

*Кереш язу үрнәге*

Кереш

Теманың *актуальлеге.*

Проблеманың *өйрәнелү дәрәҗәсе*.

Курс эшенең тикшеренү *объекты* итеп .................алынды.

Тикшеренү *предметы* булып ...............үзенчәлеге мәсьәләсе тора.

Курс эшенең *максаты* –

Курс эшенең *бурычлары*:

Курс эшенең *фәнни-нәзари методологик* нигезе булып ....хезмәтләре торды.

Курс эшенең *фәнни методлары*. Фәнни эш тасвирлау, анализлау, күзәтү алымнарына нигезләнеп башкарылды.

Курс эшенең *яңалыгы*. ............

Курс эшенең *гамәли* әһәмияте. Югары уку йортларында белем алучы студент, .....өчен кирәкле, файдалы булыр дип уйлыйбыз.

Курс эшенең *чыганаклары* булып ...........кулланылды.

Хезмәтнең *структурасы.*

*Апробация* (булса)

**Кушымта 3**

*Курс эшенең титул бите*

Россия Федерациясе фән һәм югары белем министрлыгы

Югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе

“Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты”

(ЮББ ФДБМУ “ЯДПУ”)

Филология факультеты

Рус һәм татар филологиясе кафедрасы

КУРС ЭШЕ

**Т.МИҢНУЛЛИН ИҖАТЫНДА**

**ЭМОЦИОНАЛЬ – ЭКСПРЕССИВ ЛЕКСИКА**

44.03.05 “Педагогик белем бирү”

“Туган тел һәм әдәбият”

Фәнни җитәкче:

филология фәннәре кандидаты,

доцент ____________ Хазиев Р.И.

Белем алучы 1531 төркем

_______________ Закирова А.Ш.

Яр Чаллы – 2023

**Кушымта 4**

*Курс эше эчтәлеге үрнәге*

ЭЧТӘЛЕК

Кереш........................................................................................................3

Бүлек 1. М.Хәбибуллинның “Кубрат хан” романының проблематикасы.............................................................................................5

1.1. “Проблема” төшенчәсенең асылы һәм аның типлары........................5

1.2. “Кубрат хан” романында милләтара һәм конфессиональ мөнәсәбәтләр проблемасы..............................................................................8

1.3. Шәхес иреге проблемасы..................................................................11

Бүлек 2. Урта белем бирү этабында М.Хәбибуллинның “Кубрат хан” романының проблематикасын проект технологиясе ярдәмендә өйрәнү...........15

2.1. Татар әдәбиятын өйрәнгәндә проектлар технологиясен куллану....................................................................................................15

2.2. 11 сыйныфта “Кубрат хан” романының проблематикасын проект технологиясен кулланып өйрәнү....................................................................22

Йомгак.........................................................................................................28

Кулланылган чыганаклар исемлеге........................................................30

Кушымталар

## Кушымта 5

*Кереш язу үрнәге*

### Кереш

Укучыларга тәрбия һәм белем бирүдә, аларны тормышка әзерләүдә әдәбиятның роле һәркемгә билгеле. Ул сәнгатьнең әлеге төрен мәктәптә өйрәнүнең төп максат-бурычларында да ачык чагыла: матур әдәбиятның иң гүзәл үрнәкләре белән танышу аша укучыларны күренекле әдипләрнең рухи эзләнүләренә якынайту, матурлык дөньясына алып керү, укуга теләк, кызыксыну тәрбияләү, әдәби сүзне аңларга өйрәтү, шулар нигезендә тормышка, чынбарлыкка шәхси карашларын, мөнәсәбәтләрен формалаштыру, эстетик зәвык булдыру, гомумән, заман таләпләренә җавап бирә торган шәхес тәрбияләргә булышу. Монда төп урынны, һичшиксез, әдәбият алып тора. Программа һәм дәреслекләрдә гасырлар дәвамында саналган халык иҗаты һәм язма әдәбиятның иң яхшы үрнәкләре урын алган һәм алар сыйныфтан сыйныфка киңәя, төрләнә, катлаулана барып татар әдәбиятының бай мирасы, анда якланган һәм сакланган гомумкешелек кыйммәтләре белән таныштыра, дөньяга карашны киңәйтергә, әдәби зәвыкны үстерергә, иң мөһиме, әдәби белем–күнекмәләрне формалаштырырга ярдәм итә.

Шундый әсәрләрнең берсе – Мөсәгыйт Хәбибуллинның “Кубрат хан” тарихи романы. Әлеге әсәрдә автор, тарихи чыганакларга таянып, болгар-татар бабаларыбызның борынгы дәверләрен, сикәлтәле-гыйбрәтле язмыш борылышларын хронологик тәртиптә һәм җанлы картиналарда сәнгатьчә гәүдәләндереп бирүне максат итеп куя. Әсәрне проблематика яссылыгында өйрәнү, бер яктан, Мөсәгыйт Хәбибуллин иҗатын тулырак аңларга ярдәм итсә, икенче яктан, хәзерге татар проза әдәбиятында барган эзләнүләрне тоемларга мөмкинлек бирә.

Әлеге әсәрне яңа технологияләр ярдәмендә мәктәптә өйрәнү буенча

махсус хезмәтләр юк. Сайланылган теманың *актуальлеге* әнә шулар белән билгеләнә.

Фәнни эшебезнең максаты – 11 сыйныфта М.Хәбибуллинның “Кубрат хан” романының проблематикасын өйрәнү үзенчәлекләрен тикшерү.

Билгеләнгән максатыбызга ирешү юлында түбәндәге *бурычларны* чишү мөһим: “Проблема” төшенчәсенең асылын һәм аның типларын ачыклау; Мөсәгыйт Хәбибуллинның “Кубрат хан” әсәрендә күтәрелгән проблемаларны аерып чыгару; аларны 11 сыйныфта өйрәнү мөмкинлекләрен тикшерү.

Тикшеренү *объекты* – М.Хәбибуллинның “Кубрат хан” романы. *Предметы* – мәктәптә М.Хәбибуллинның “Кубрат хан” романының проблематикасын проект технологиясе ярдәмендә өйрәнү.

Тикшерүнең *фәнни-теоретик базасын* күренекле галимнәр хезмәтләрендәге фәнни нигезләмәләр тәшкил иттеләр. Безнең тарафтан сайлап алынган тема һәм проблема татар әдәбиятында башлыча әдәбият белеме сүзлекләрендә, аерым фәнни мәкаләләрдә күзәтелә. Эш барышында татар галимнәреннән Д.Ф.Заһидуллина, В.Р.Әминева, М.И.Ибраһимов, Н.М.Йосыпова, Ә.М.Закирҗанов, Т.Ш.Гыйләҗев, Г.Р.Гайнуллина, Ф.М.Хатипов, Л.Хуснутдинова һ.б.ларның, рус галимнәреннән М.М.Бахтин, Е.Б.Борисова, А.Б.Есин, В.Б.Катаев, Г.Н.Поспелов, А.П.Скафтымов һ.б.ларның хезмәтләре файдаланылды. Моннан тыш, әдип иҗатына багышлап язылган тәнкыйди һәм фәнни мәкаләләр таяныч булдылар.

Тикшерү материалының характерына, курс эшенең проблематикасына бәйле рәвештә герменевтика методы – мәгънәләрне интерпретацияләү, әдәби текстның эчтәлеген ачыклау һәм системалы анализ ясау методлары кулланылды. Әсәрнең әдәби структурасын бербөтен система итеп анализлау принципларына таянып, шулай ук чагыштыру-тарихи, әдәби-тарихи, чагыштыру – капма-каршы кую, тасвирлау *алымнары һәм методлары* файдаланылды.

Әлеге хезмәт – Мөсәгыйт Хәбибуллинның “Кубрат хан” романының

проблематикасын мәктәптә өйрәнүгә багышланган беренче тәҗрибә. Язучының “Кубрат хан” әсәре хәзерге заман таләпләре нигезендә яңача караштан чыгып өйрәнелә. Хезмәтнең *фәнни яңалыгы* куелган проблеманы аерым материал нигезендә хәл итүдәге конкрет мәсьәләләрдә, анализлауда һәм нәтиҗәләрдә чагылыш табуда.

Фәнни хезмәтнең *теоретик әһәмияте* шунда, ул Мөсәгыйт Хәбибуллинның иҗади мирасын тирәнтен өйрәнү һәм XX гасырның икенче яртысындагы татар әдәбиятын системалы күзаллау өчен чыганаклар базасын киңәйтә һәм баета.

Фәнни эшебез материалы татар әдәбияты тарихын өйрәнгәндә, татар әдәбияты буенча дәреслекләр, укыту-методик әсбаплар, уку программалары төзегәндә, шулай ук югары уку йортларының филология факультеты студентларына, мәктәп-гимназия укучыларына лекция-дәресләр укыганда, студентларның фәнни-тикшеренү эшләрендә дә файдаланыла ала, дип фаразлыйбыз.

Хезмәтебез кереш, тематик яктан аерымланган ике бүлек, йомгак һәм кулланылган әдәбият исемлегеннән гыйбарәт. Кушымталарда проект барышында укытучы һәм укучы эшчәнлеге, проект эшен бәяләү критерийлары тәкъдим ителә.

*Хезмәтнең апробациясе.* Курс эше материалы нигезендә Яр Чаллы шәһәренең “Ак мәчет” мәдрәсәсендә уздырылган III Халыкара фәнни-гамәли конференциясендә “Мөсәгыйт Хәбибуллинның “Кубрат хан” романында милләтара һәм конфессиональ мөнәсәбәтләр проблемасы” (2018 ел), “XXI гасыр чакыруы: заман таләп иткән компетенцияләр” Бөтенрәсәй фәнни-гамәли конференциясендә “Мөсәгыйт Хәбибуллинның “Кубрат хан” романында күтәрелгән проблемалар” (2018 ел) дип исемләнгән чыгышлар ясалды.